**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чәкән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**05 декабрь 2021 ел** **№1**

2003 елнын 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 05 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

1. «Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Чәкән торак пунктында Яңа урам буенча жирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау);
- Чәкән торак пунктында җирлекне яктырту Һәм буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);
- Чәкән авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Чәкән торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Чәкән авылы торак пунктында балалар спорт комплексын сатып алу, җыю, урнаштыру.

2. “2020 елда Чәкән авылындагы Ык елгасы аша күперне ремонтлауга каралган һәм файдаланылмаган 5 мең сум күләмендәге үзара салым акчаларын 2022 елда Чәкән торак пунктының Яңа урам буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау) юнәлдерергә.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 205 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 133.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларнын тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе очен 133, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - гамәлдә дөрес дип танырга.

2.Түбәндәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Чәкән торак пунктында Яңа урам буенча жирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау);

- Чәкән торак пунктында җирлекне яктырту Һәм буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);

- Чәкән авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);

- Чәкән торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Чәкән авылы торак пунктында балалар спорт комплексын сатып алу, җыю, урнаштыру.

2. “2020 елда Чәкән авылындагы Ык елгасы аша күперне ремонтлауга каралган һәм файдаланылмаган 5 мен сум күләмендәге үзара салым акчаларын 2022 елда Чәкән торак пунктының Яңа урам буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау) күчерелүе белән килешәсезме?”

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматынын рәсми сайтында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районынын Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: И.Б. Бохарова